| СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2015 г.Агрыз № 41-6

Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында 2014 елның 30 октябрендәге 36-4 номерлы Әгерҗе муниципаль районы Советы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында»гы 25.12.2008 елдагы 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында"гы 23.03.2015 № 308-ПУ Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2014 елның 30 октябрендәге 36-4 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы»

Әгерҗе муниципаль районы «муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында» гы 36-4 номерлы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1.2 пунктында «Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә билгеләнгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган, шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган, һәм шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти, һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат исемлеген раслау турында, «шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары» сүзләрен алып ташларга;

1.2. Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәнең 7 пунктындагы «в» пунктчасында, алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) уртак кеременнән артса «сүзләрен» әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артса «сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 13 пунктында
"алыш-биреш башкарылган" сүзләрен «алыш-биреш ясалган»сүзләренә алмаштырырга;

алыш-биреш суммасы муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артса «сүзләрен» әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның һәм аның

хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артса» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районының agryz.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча Даими комитетына йөкләргә (И. М. Карамиев)

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы В.В.МАКАРОВ